КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2021 ел, 11 гыйнвар г.Казань № 1

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2007 ел, 14 декабрь, 717 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы коллегиясе составына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы коллегиясе составын раслау турында» 2007 ел, 14 декабрь, 717 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2008 ел, 15 февраль, 83 нче; 2008 ел, 25 июнь, 440 нчы; 2008 ел, 21 июль, 518 нче; 2009 ел, 27 февраль, 114 нче; 2010 ел, 11 гыйнвар, 2 нче; 2010 ел, 16 сентябрь, 741 нче; 2011 ел, 26 декабрь, 1067 нче; 2014 ел, 12 апрель, 235 нче; 2014 ел, 17 ноябрь, 883 нче; 2015 ел, 4 февраль, 58 нче; 2015 ел, 6 апрель, 223 нче; 2015 ел, 30 октябрь, 818 нче; 2016 ел, 31 август, 603 нче; 2017 ел, 7 июнь, 351 нче; 2018 ел, 19 апрель, 266 нчы; 2019 ел, 5 декабрь, 1101 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы коллегиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

коллегия составына Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы каршындагы Иҗтимагый совет рәисе Маргарита Николаевна Максимованы кертергә;

Борис Федорович Захаровның вазыйфасы исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«һөнәр берлекләренең югары белем бирүче «Хезмәт һәм социаль мөнәсәбәтләр академиясе» мәгариф учреждениесенең Казан филиалы директоры киңәшчесе (килешү буенча)».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин